**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ НОВОАЛИМОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423762, село Новое Алимово, улица Г.Тукая, дом 55.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423762, Яңа Әлем авылы . Г.Тукай урамы, 55 йорт.

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«27» февраль 2021 ел** **№2**

**Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советының 07.09.2017ел №25 «Яңа Әлем авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив-хокукый актларны «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советының 07.09.2017 ел №25 «Яңа Әлем авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11.2. бүлек, Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 12 нче абзац белән тулыландырырга:

«12) җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Яңа Әлем авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Яңа Әлем авыл җирлеге
Советы Башлыгы Д.М.Анварова